# Рахматуллина Айгуль Абузаровна

Учитель истории и обществознания

МБОУ - Малокибякозинская основная общеобразовательная школа

Тюлячинского муниципального района Республики Татарстан

# Патриотизм тамырлары



**Туган җир! Туган төбәк ! Туган табигать!** Һәр кеше өчен нинди газиз, тирән мәгьнәле сүзләр! Туган як кеше өчен ата - анасы кебек үк кадерле. Туган туфрагында кеше аягына баса, тәпиләп китә, шуннан аның теле ачыла, ул тәүге сүзен әйтә.Торган саен син туган якның гүзәллеген ныграк аңлыйсың, байлыкларын күз алдына ачыграк китерәсең. Бу сүзләр мәгънәсенә шулай ук әти, әни, әби, бабай, безнең якын кешеләребез, гомумән, барлык тереклек дөньясы керә.

Кеше кайда гына булмасын, ул иң беренче чиратта, әти-әнисен, туган ягын искә төшерә, алар белән бәйләнешле истәлекләрен яңарта. Ләкин алар турында уйланмау, әлеге төбәкнең тарихын, бүгенгесен белмәү, кызыксынмау аны яратмауга тиң. Без үзебез яши торган туган төбәгебезне белергә, өйрәнергә, яратырга, сакларга, чын патриоты булырга тиеш.

# Кем ул патриот?

**Патриот – үзенең туган җирен, халкын, илен , ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга әзер булган кеше.**

# Нәрсә ул *патриотизм?*

**Патриотизм - чувство гордости за свою нацию и стремление к ее возвеличиванию.**

**Патриотизм – патриотларга хас булган күренеш, үзеңнең милләтең, Ватаның өчен горурлык хисе һәм аны олылауга омтылыш.**



**Патриотизм тамырлары, халкыбызның үткәненә, ерак бабаларыбызның Ватан өчен кыелган җаннарына барып тоташа.**

**Тарихыбыздагы героик сәхифәләрнең иң зурысы булып Бөек Ватан сугышы тора.**







- Сугышның һәр көнендә 14000 кеше һәлак булган. Бу исә 1 минутка 10 кеше һәлак булган дигән сүз.
- Мәскәүдән Берлинга кадәр араның һәр километрында уртача 7500 кеше яу кырында мәңгелеккә ятып калган.
- Менә бу Җиңү күпме корбаннар исәбенә яуланды.

**Теләче районыннан Бөек Ватан сугышына 4430 кеше китә, шуларның 1386 сы гына әйләнеп кайта. Теләче районы Әбде авылы егете Александр Кузьмич Ксенофонтов  Советлар Союзы герое исеменә лаек була.Батыр якташыбыз финнар белән булган каты бәрелешләрнең берсендә, Казан дивизиясе составында, командиры – Казан егете Хафиз Сабиров җитәкчелегендә сугышканда һәлак булган. Х. Сабиров та батырларча үлә, герой исеменә тәкъдим ителә.**



**Безнең Кече Кибәхуҗа җирле үзидарә территориясеннән сугышка**

**291 кеше киткән, шуларның 143 е генә туган авылына әйләнеп кайта алган. Тыл хезмәтендә авылдашларыбыз фидакарь хезмәт куйганнар.**

**1941-1945 елларда**

**48 кеше “За доблестный труд во время Великой Отечественной войны” медале белән бүләкләнгән.**



*Ул, Алтын Йолдызы булмаса да,*
*чын Герой иде...*




Морат Мостафин

*“...Легендар С.А. Ковпак җитәкчелек ит – кән партизаннар берләшмәсендә иң яхшы төркем командирларыннан саналган Морат Әхмәтсафа улы Мостафин 1942 елның 25 маенда дошманга каршы көрәштә батырларча һәлак булды.Татарстанның Теләче районы Олы Кибәхуҗа авылыннан бу ир – егет - данлыклы татар халкының һәм бөтен совет халкының тугрылыклы улы иде. Мин М.Ә. Мостафинны яхшы белә идем, аның белән бергә күп мәртәбәләр фашистларга каршы көрәштем. Морат Әхмәтсафа улы кыю, Ватан-анага чиксез бирелгән егет иде. Ул, Алтын Йол-дызы булмаса да, чын Герой иде.” ( С.А. Ковпак партизан берләшмәсендәге элеккеге политрук, СССР чорында Украина ССРның югары һәм урта белем бирү министры урынбасары булып эшләгән Л.Е.Кизя). Эзтабарлык эше белән журналист Шаһинур Мостафин шөгыльләнә.*

# Гаилә истәлекләреннән...







***Морат Мостафинның хәләл җефете Миңнемахруйбикә Насибулла кызы. Морат батырның әнисе Зәйнәпбикә (уңда), бертуган сеңлесе Ләбибә улы Наил белән.***

***Морат Мостафинның кызы Флера апа гаиләсе белән***




***Илебез халкына төшкән тагын бер газап – ул Әфганстан,Чечня сугышы. Анда күпме егетләребез зур батырлыклар эшләп үзләренең тормышларын бирделәр. Безнең авылыбыз солдатлары да читтә калмадылар Алар: Шәяхмәтов Фидаил, Шәяхмәтов Равил, Закиров Миннулла, Гыйльметдинов Илсур, Закиров Фәнил абыйларыгыз. Армия сафларына барыр вакытлары җиткән солдатларга хезмәт итү урынын сайлап алып булмый. Ватан кая куша, шунда хезмәт итәсе. Ә бу солдатларга башка ил мәнфәгатьләрен кайгыртырга туры килә. Шунысы яхшы, барып үз бурычын үтәгән бу солдатларыбыз барысы да исән-сау. Очрашуларда, бу геройлар, үзебезнең бурычны гына үтәдек, диләр. Сусыз, таулы, эссе һавалы бу илләрдә һәрнәрсәгә түзем,чыдам, көчле булу да ярдәм итә үзләренә. Ә укучыларга алар сәламәт булу өчен чыныгырга, һәр эшне җаваплылык белән төгәл эшләргә өйрәнергә, ныклы белем алырга дип киңәшләрен бирәләр.***







***Армиядә хезмәт итү – һәр ир – егетнең изге бурычы. Туган илне саклау, дусларыңны, халкыңны яклау өчен йокысыз төннәреңне, белемеңне, көчеңне бирәсең икән – бу зур батырлык. Моның өчен  егетләребездән бик күп сабырлык, түземлелек, җитезлек, кыюлык таләп ителә. Безнең  Кече Кибәхуҗа авыл җирлегендә яшәүче егетләребез бу вазифаны намус белән башкаралар. Командирлары тарафыннан мактау, рәхмәт хатлары килеп тора.***



*Бүгенге көндә Олы Кибәхуҗа авылы егете Солтангәрәев Илнур үзенең изге бурычын намус белән башкара.*



## Йомгаклау:

***-Һәркем үз иленең патриоты булырга тиеш, шунсыз дәүләт тотрыклы һәм тыныч яши алмастыр.***



# Интернет ресурслар:

http://nsportal.ru/shkola/vneklassnaya-rabota/library/patriotizm-tamyrlary

http://edu.tatar.ru/tulachi/m-kibyakozi/sch

http://festival.1september.ru/articles/565854/

http://yandex.ru/yandsearch?text=%D0%BA%D0%B0%D1%80%D1%82%D0%B8%D0%BD%D0%BA%D0%B8%20%D0%B2%D0%B5%D0%BB%D0%B8%D0%BA%D0%BE%D0%B9%20%D0%BE%D1%82%D0%B5%D1%87%D0%B5%D1%81%D1%82%D0%B2%D0%B5%D0%BD%D0%BD%D0%BE%D0%B9%20%D0%B2%D0%BE%D0%B9%D0%BD%D1%8B&clid=740031&lr=43